Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Күгәш авылы
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«15» ноябрь 2025 ел № 2

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Сәмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлегенең 01.11.2019 ел «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Сәмәкәй авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында «42/2 номерлы»нигезләмәне раслау хакында", нигезендә Сәмәкәй авыл җирлеге Күгәш авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2026 елда яшәү урыны буенча Сәмәкәй авыл җирлеге Күгәш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 600 (алты йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

**-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (чокыр ремонтлау, юллар төзү, вак таш сатып алу, махсус техника хезмәтләре);**

2. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Күгәш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка житкерергә.
3. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Күгәш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сәмәкәй авыл җирлеге Башлыгы И.М.Усманов